КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1055

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2023 ел, 30 декабрь, 1757 нче карары белән расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2023 ел, 30 декабрь, 1757 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 29 июнь, 478 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлектә:

2 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«клиник тәкъдимнамәләр нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән көндезге стационар шартларында онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча клиник тәкъдимнамәләр һәм критерийлар нигезендә көндезге стационар шартларында онкология авырулары белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү;»;

3 пунктта:

өченче абзацта «күзәтү» сүзеннән соң «(эшләүче гражданнарны диспансер күзәтүне дә кертеп)» сүзләрен өстәргә;

утыз бишенче абзацта «2025» саннарын «2024» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Иминият медицина оешмалары мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында гамәлгә ашырылган барлык экстракорпораль аталану очракларының сыйфатына (аның нәтиҗәлелеген бәяләүне (йөккә узу фактын) кертеп) экспертиза уздыра. Экспертиза нәтиҗәләре иминият медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына җибәрелә һәм медицина оешмаларына экстракорпораль аталандыру буенча медицина ярдәме күләмен бүлү турындагы мәсьәләләрне хәл иткәндә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын әзерләү комиссиясе утырышларында карала.»;

V бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хроник бөер җитешсезлеге белән интегүче пациентларны фактта яшәү урыннан бөер функцияләрен алмаштыра торган дәвалау ысулы белән гамәлгә ашырыла торган медицина ярдәме күрсәтелү урынына кадәр алып бару һәм аннан кире алып кайту.

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең тиешле субъекты арасында төзелә торган, мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авыру белән авырганда медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплау мәсьәләсен ике яклы җайга салуны үз эченә ала торган төбәкара килешү нигезендә түбәндәгеләргә чыгымнарны каплау гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авыру белән авырганда медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәткән Россия Федерациясе субъектына;

республика медицина оешмалары тарафыннан Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авыру белән авырганда медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтелгән өчен Татарстан Республикасына.»;

VI бүлектә:

1 бүлекчәнең 1.5 пунктындагы алтынчы абзацында «туклану» сүзеннән соң «(шул исәптән хәрби хәрәкәтләр ветераннары өчен)» сүзләрен өстәргә;

4 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Халыкның аерым категорияләре өчен диспансеризация үткәрү, балигъ булмаганнарны профилактик карау шартлары һәм сроклары, гражданнарга диспансер күзәтү

Халыкны диспансеризацияләү чаралар комплексыннан, шул исәптән табиб-белгечләр тарафыннан медицина тикшерүеннән һәм халыкның аерым төркемнәренә, шул исәптән балигъ булмаганнарның аерым категорияләренә карата гамәлгә ашырыла торган тикшерүнең кирәкле ысулларын куллануdan гыйбарәт. Халыкны диспансеризацияләү авыруларны иртәрәк ачыклауга һәм профилактикалауга юнәлдерелгән.

Балигъ булмаганнарга профилактик медицина тикшерүләре патологик хәлне, авыруларны һәм аларның үсеш рискы факторларын иртәрәк (үз вакытында) ачыклау, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне медицинада кулланмау максатларында, шулай ук сәламәтлек төркемнәрен билгеләү һәм балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары яисә башка законлы вәкилләр өчен тәкъдимнәр эшләү максатларында, билгеләнгән яшь чорларында уздырыла.

Балигъ булмаганнарны диспансеризацияләү һәм аларга профилактик медицина тикшерүләре, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясында билгеләнгән таләпләрне үтәп, балигъ булмаганнарның (аның ата-анасының яки башка законлы вәкиленең) мәгълүмат алу характерындагы ирекле ризалыгы булу шарты белән Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив документларында расланган программалар һәм сроклар нигезендә Мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасын тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмаларында уздырыла.

Медицина оешмасында кирәкле табиб-белгечләр, лаборатор һәм функциональ тикшеренүләр булмаганда, халыкка, шул исәптән балаларга профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация үткәрү өчен белгечләр консультацияләре һәм диагностик тикшеренүләр башка медицина оешмаларының белгечләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итеп үткәрелергә мөмкин.

Табиб-белгечләр тарафыннан тикшерүләр, үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, профилактик чаралар үткәрү һәм дәвалау буенча табиб-белгечләрнең тәкъдимнәре, шулай ук сәламәтлек торышына комплекслы бәя бирелгән гомуми бәяләмә билгеләнгән тәртиптә медицина документациясенә кертелә.

Профилактик чаралар үткәрү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гражданнарның профилактик медицина тикшерүләре, диспансеризация, шул исәптән эш көннәрендә һәм шимбә кичке сәгатьләрдә узуын оештыруны тәэмин итә, шулай ук гражданнарга шул исәптән турыдан-туры, телефон аша һәм дистанцион рәвештә медицина тикшеренүләренә язылу мөмкинлеген бирә. Профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация үткәрү графигы медицина оешмасы тарафыннан медицина оешмасына керү урынында урнашкан стендта һәркем күрә торган итеп, шулай ук медицина оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Хәрби хәрәкәтләр ветераннары, шул исәптән махсус хәрби операциядә кат-

нашучы хәрби хәрәкәтләр ветераннары чираттан тыш тәртиптә диспансеризация һәм профилактик тикшерүләр узарга хокуклы.

Иминләштерелгән затларга профилактик тикшерүләр, диспансеризация һәм диспансер күзәтүләрен үткәрү тәртибе, шул исәптән эш көннәрендә кичке сәгатьләрдә һәм шимбәдә Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Профилактик чаралар шул исәптән халык үлеменең төп сәбәпләре булып торган кан әйләнеше системалары авыруларын һәм онкология авыруларын ачыклау өчен, эндокрин системасы, ашкайнату органнары авыруларын һәм башка авыруларны ачыклау өчен, шулай ук хатын-кызларның һәм ир-атларның репродуктив сәламәтлеген бәяләү өчен оештырыла.

Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авырып алган гражданнар, авырганнан соң, бер ел эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы турында» 2023 елның 28 декабрендәге 2353 номерлы карары белән расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына 5 нче кушымта нигезендә исемлек буенча тикшеренүләрне һәм башка медицина катнашуларын үз эченә алган тирәнтен диспансеризация (алга таба – тирәнтен диспансеризация) узарга хокуклы.

Тирәнтен диспансеризация шулай ук яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авырып алуы турында мәгълүматлары булмаган гражданның инициативасы белән дә үткәрелергә мөмкин.

Гражданнарны тирәнтен диспансеризация (беренче чиратта тирәнтен диспансеризация уза торган категорияләрне кертеп) узарга җибәрү тәртибе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Беркетелгән контингенты булган медицина оешмалары, шул исәптән гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә федераль башкарма хакимият органнары гамәлгә ашыра торган медицина оешмалары (алга таба – федераль медицина оешмалары) гражданнарны (беренче чиратта тирән диспансеризация узучы гражданнар категорияләрен кертеп) тирәнтен диспансеризация узуга җибәрү тәртибе нигезендә тирәнтен диспансеризация узарга тиешле гражданнар исемлеген төзиләр, һәм аны Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына җибәрә. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды мәҗбүри медицина иминиятенең дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә әлеге исемлекләрне тирәнтен диспансеризация узарга тиешле гражданнар иминләштерелгән иминият медицина оешмаларына җиткерә.

Гражданнарга тирәнтен диспансеризация узу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, радиотелефон элемтәсе челтәрен (СМС-хәбәрләр) һәм һәркем файдалана торган башка элемтә чараларын кулланып, иминият медицина оешмаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны тирән диспансеризация язу шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт

мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Медицина оешмалары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы турында» 2024 елның 28 декабрендәге 2353 номерлы карары белән расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына 5 нче кушыматаның 1 пункты нигезендә, тирәнтен диспансеризациянең беренче этабындагы барлык тикшеренүләрдән һәм башка медицина катнашуларыннан чыгып, бер көн эчендә гражданның тирәнтен диспансеризация узуын оештыра.

Тирәнтен диспансеризация нәтиҗәләре буенча хроник йогышлы булмаган, шул исәптән авырып алган яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән бәйле авырулар ачыкланган очракта, граждан өч эш көне дәвамында билгеләнгән тәртиптә өстәмә тикшерүләргә җибәрелә, диспансер күзәтүенә куела. Күрсәтмәләр булган очракта, аңа Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле дәвалау һәм медицина реабилитациясе күрсәтелә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә дару препаратлары бирелә.

Профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация, шул исәптән тирәнтен диспансеризация узу кысаларында медицина тикшеренүләрен үткәрү өчен кирәк булганда, медицина оешмаларының стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләре җәлеп ителергә мөмкин.

Репродуктив яшьтәге хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен этаплап, яшь төркемнәренә карап, аларның репродуктив сәламәтлеген бәяләүгә юнәлдерелгән диспансеризация (алга таба – хатын-кызларның һәм ирләрнең репродуктив сәламәтлеген бәяләү өчен диспансеризация) уздыру Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оештырыла.

Граждан беркетелгән медицина оешмасында барлык тикшеренүләрне үткәрү мөмкин булмаганда, әлеге тикшеренүләрне үткәрү өчен граждан беркетелгән медицина оешмасының медицина хезмәткәре тарафыннан тикшерү өчен материал алу гамәлгә ашырыла һәм аны башка медицина оешмасына, шул исәптән федераль медицина оешмасына билгеләнгән тәртиптә җибәрү башкарыла. Граждан беркетелгән медицина оешмасында табиб – акушер-гинеколог, табиб-уролог (репродуктив сәламәтлек мәсьәләләре буенча әзерлек узган табиб-хирург) булмаган очракта, әлеге медицина оешмасы диспансеризация үткәрү өчен гражданга, кабул итү (карау) датасы билгеләнгәнгә кадәр кимендә өч эш көне кала әлеге табибларның эш көне һәм вакыты турында мәҗбүри хәбәр итеп, башка медицина оешмаларының тиешле табибларын (шул исәптән аларның күчмә эш рәвешләренә карап) җәлеп итә.

Репродуктив сәламәтлекне бәяләү буенча өлкән яшьтәге репродуктив яшьтәге халыкка диспансеризация үткәрү кысаларында уздырыла торган тикшеренүләр һәм башка медицина катнашулары исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы турында» 2024 елның 28 декабрендәге 2353 номерлы карары белән расланган 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына 6 нчы кушыматада китерелде.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гражданнар профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация уза алган медицина оешмалары турында (хатын-кызларның һәм ирләрнең репродуктив сәламәтлеген бәяләү өчен тирәнтен диспансеризация һәм диспансеризация үткәрүче медицина оешмалары исемлеген, шулай ук аларның эш тәртибен кертеп) мәгълүмат урнаштыра.

Профилактик медицина тикшерүләрен һәм диспансеризацияне гражданның яшәү, эшләү яисә уку урынына якынайту максатларында медицина оешмалары күчмә медицина бригадаларын формалаштыра. Медицина оешмалары җиде календарь көн кала диспансеризация узарга тиешле һәм медицина бригадасы бара торган урында яши торган гражданнар беркетелгән иминият медицина оешмаларына мондый бригаданың бару датасы һәм урыны турында хәбәр итә. Иминият медицина оешмалары, үз чиратында, өч көн кала медицина бригадасы бара торган урында яши торган, иминләштерелгән затларга медицина бригадасының килү датасы һәм профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация уздыру урыны турында хәбәр итә, шулай ук әлеге тикшерүләргә гражданнар килү мониторингын гамәлгә ашыра, тиешле мәгълүматларны мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондларына тапшыра.

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды хатын-кызларның һәм ирләрнең репродуктив сәламәтлеген бәяләү өчен профилактик медицина тикшерүләре, диспансеризация, тирәнтен диспансеризация һәм диспансеризация үткән затлар саны, уздырылган чараларның нәтиҗәләре турында мәгълүматлар җыюны гамәлгә ашыра һәм агрегирлаштырылган белешмәләрне Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыра.

Профилактик медицина тикшерүләрен, шул исәптән диспансеризация (тирәнтен диспансеризацияне кертеп) кысаларында уздыру буенча медицина хезмәткәрләренең хезмәте өчен өстәмә түләү, алар өчен билгеләнгән эш вакыты озынлыгыннан чыгып эшләүне исәпкә алып, Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Профилактик медицина тикшерүе, диспансеризация үткәргәндә гражданның медицина документлары белән расланган, элегрәк үткәрелгән (бер елдан да соң булмаган) медицина тикшерүләре, диспансеризация нәтиҗәләре (профилактик медицина тикшерүе һәм диспансеризация кысаларында тикшеренүләрне һәм башка медицина чараларын кабат уздыру өчен медицина күрсәткечләре булуын дәлилли торган авырулар симптомнары һәм синдромнары булуы ачыкланган очраклардан тыш) исәпкә алынырга мөмкин.

Диспансеризация узганнан соң бер ел эчендә гражданның диспансеризация вакытында билгеле була алган авыруы ачыкланган очракта, иминият медицина оешмасы әлеге очрак буенча медицина-икътисадый экспертиза, ә кирәк булганда Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган тәртиптә медицина ярдәме сыйфатына экспертиза үткәрә. Әлеге экспертизалар нәтиҗәләре Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенә тикшереп карау һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү өчен җибәрелә.

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хәрәкәтләр ветераннарын диспансеризацияләүне оештыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу куркынычы барлыкка килү шартларында, шулай ук башка үткен респиратор вируслы инфекцияләр таралган очракта, мәҗбүри медицина иминиятенең база программасын тормышка ашыру үзенчәлекләрен исәпкә алып, профилактик чаралар үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

Диспансер күзәтүе, авыруларны вакытында ачыклау, катлауолануларны кисәтү, авыруларның кискенләшүе, башка хәлләр, аларны профилактикалау һәм медицина реабилитациясен гамәлгә ашыру максатларында, хроник авырулар, функциональ тайпылышлар, башка хәлләр белән интегүче затларга билгеле бер вакыт саен кирәкле тикшерүне үткәрүдән гыйбарәт.

Диспансер күзәтү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган тәртиптә уздырыла.

Диспансерлык кабул итүләренең (карауларның, консультацияләрнең) әледән-әле үткәрелүен бәяләү иминият медицина оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла, идарә карарларын анализлау һәм кабул итү өчен диспансер кабул итүләренең (карауларның, консультацияләрнең) әледән-әле үткәрелүе сакланмау фактлары турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фондына тапшырыла.

Медицина оешмалары, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, шулай ук иминият медицина оешмаларын җәлеп итеп, диспансер күзәтүе билгеләнгән, иминләштерелгән затка диспансер кабул итүгә (карауга, консультациягә) килү өчен тәкъдим ителә торган сроклар турында хәбәр итә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы үз компетенциясе чикләрендә эш бирүченең эшләүче гражданнарга һәм (яисә) мәгариф оешмаларында укучыларга медицина хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында һәм (яисә) мәгариф оешмасында һәм аларның структур бүлекчәләрендә (табиб кабинеты, сәламәтлек пункты, медицина кабинеты, медицина өлеше һәм башка бүлекчәләр), ә эш бирүченең һәм (яисә) белем бирү оешмасының (структур бүлекчәнең) мондый медицина оешмасы булмаганда килешенгән медицина оешмасында диспансер күзәтүен үткәрү өчен шартлар тудыра.

Эшләүче иминләштерелгән затларга карата хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча һөнәри авыруларны яки катлауолануларны үстерүне, элек формалашкан хроник йогышлы булмаган авыруларны кискенләштерүне профилактикалау максатларында диспансер күзәтүе үткәрү оештырылырга мөмкин.

Эшләүче гражданнарны диспансер күзәтүне оештыру түбәндәгечә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

эш бирүченең оешма хезмәткәрләренә үз көчләре һәм чаралары белән медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәсе (табиб кабинеты, сәламәтлек пункты, медицина кабинеты, медицина часте һәм башка бүлекчәләр) булганда;

эш бирүченең әлеге бүлекчәсе булмаганда, ММИ база (территориаль) программасында катнашучы һәм эшләүче гражданга диспансер күзәтү үткәрү өчен кирәкле матди-техник базасы һәм медицина хезмәткәрләре булган теләсә кайсы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмасы белән шартнамә төзү юлы белән (мондый медицина ярдәме өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә счетларның аерым реестрлары буенча түләү белән).

Эш бирүче белән әлеге медицина оешмасы арасында эшләүче гражданнарга диспансер күзәтүе уздыру турында шартнамәнең билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе медицина оешмасы тарафыннан счетларның аерым реестрлары кысаларында эшләүче гражданнарга диспансер күзәтүе буенча комплекслы булуларга алга таба түләү максатларында Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте фондына җибәрелә.

Эшләүче гражданның диспансер күзәтүе шулай ук эшләүче граждан беркетелгән медицина оешмасы көче белән, күчмә эш ысулларын кулланып һәм гражданның хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча тикшерүләрне һәм карауларны оештырып, башкарылырга мөмкин.

Әгәр Программаның әлеге бүлеге нигезендә эшләүче гражданның диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы медицина оешмасы эшләүче граждан беркетелгән медицина оешмасы булмаса, бу оешма әлеге нәтиҗәләр алынганнан соң өч эш көне эчендә, «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, эшләүче гражданның диспансер күзәтүен узу нәтиҗәләре турында белешмәләрне граждан беркетелгән медицина оешмасына җибәрә.

Бу очракта Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды әлеге күзәтүне кабатлауны булдырмау максатларында эшләүче гражданнарның уздырылган диспансер күзәтүен исәпкә алу дөреслеген контрольдә тота.

Эшләүче гражданнарны диспансер күзәтүен уздыру тәртибе һәм медицина оешмалары арасында мондый диспансер күзәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат алмашу тәртибе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды эшләүче гражданнарны диспансер күзәтүен уздыруның барлык очракларын (иминләштерелгән һәр эшләүче граждан яктылыгында) исәпкә алуны башкара, ай саен тиешле шәхсисезләштерелгән мәгълүматларны Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына тапшыра.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы эшләүче гражданнарга диспансер күзәтүен уздыру тәртибе буенча аңлатмалар бирә, шулай ук аны мониторинглый. Эшләүче гражданнарны диспансер күзәтүе өчен түләү тәртибе буенча аңлатмалар Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды тарафыннан бирелә.»;

18 бүлекчәнең соңгы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

VII бүлекнең 1 таблицасында:

II бүлекнең 2 пунктында:

2.1.3.2 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

2.1.7.3 пунктчадан соң түбәндәге эчтәлекле 2.1.7.4 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.1.7.4. Эшләүче гражданнарны диспансер күзәтү | комплекслы булулар | 0,034623 | 2 288,8 | 0,034623 | 2 430,7 | 0,034623 | 2 574,1»; |

2.1.8 пунктчадан соң түбәндәге эчтәлекле 2.1.9 пунктчасы өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.1.9. Репродуктив сәламәтлекне бәяләү өчен диспансеризация кысаларында булулар | комплекслы булулар | 0,013421 | 3 650,1 | 0,013421 | 3 876,1 | 0,013421 | 4 104»; |

III бүлекнең 6 пунктында:

6.1.2 пунктчадан соң түбәндәге эчтәлекле 6.1.2.1 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.1.2.1. шул исәптән балалар өчен | булулар | 0,00115 | 2 514,0 | 0,00115 | 2 703,0 | 0,00115 | 2 906,1»; |

6.2 пунктчадан соң түбәндәге эчтәлекле 6.2.1 пунктча өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.2.1. шул исәптән балалар өчен | койка-көн | 0,00316 | 2 992,3 | 0,00316 | 3 248,0 | 0,00316 | 3 515,3»; |

1 нче таблицаның 7 нче астөшермәсенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2024 – 2026 елларга стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында (балалар интернат йортларында) яшәүче балаларны диспансеризацияләү кысаларында бер комплекслы булуга финанс чыгымнары нормативы 4 136,45 сум тәшкил итә.»;

1,5, 6 нчы кушымталарны (карарга теркәләләр) яңа редакциядә бәян итәргә;

8 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 2 ноябрь, 957 нче
карары редакциясендә)

# 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында, шул исәптән мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын гамәлгә ашыруда катнашучы медицина оешмалары исемлеге һәм 2024 елда профилактик медицина тикшерүләре һәм диспансеризация, шул исәптән тирәнтен диспансеризация уздырыла торган медицина оешмалары исемлеге

| Т/с | Реестр буенча медицина оешмасының коды | Медицина оешмасының исеме | Шул исәптән* | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре акчасы исәбеннән дәүләт биремен үтәү кысаларында эшчәнлек гамәлгә ашыручы | мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек гамәлгә ашыручы | шулардан | | | | | | | |
| | | | | | профилактик медицина тикшерүе һәм диспанризация үткәрүче | шул исәптән | | диспансер күзәтүен үткәрүче | медицина реабилитациясен үткәрүче | шул исәптән | | |
| | | | | | | тирәнтен диспансризация | хатын-кызларның һәм ир-атларның репродуктив сәламәтлеген бәяләү өчен | | | Амбулатор шартларда: | көндезге стационарлар шартларында: | тәүлек буе эшли торган стационар шартларында |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | 166602 | [1]«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУ** | 1 | 1 | 1 | | | | 1 | 1 | 1 | 1 |
| 2. | 166637 | «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» ДАССУ** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 3. | 166601 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министр- | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | 1 | | | 1 |

[1]Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 12 биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | лыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ**,*** | | | | | | | | | | |
| 4. | 166219 | «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 5. | 166203 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор Е.В.Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» ДАССУ** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 6. | | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 7. | 166205 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы» ДАССУ*** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 8. | | «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 9. | 166208 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г.Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» ДАССУ** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 10. | 166703 | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор М.З.Сигал исемендәге Республика клиник онкология диспансеры» ДАССУ** | 1 | 1 | | | | 1 | 1 | | 1 | 1 |
| 11. | | «Республика клиник туберкулезга каршы диспансеры» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 12. | | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник наркология диспансеры» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 13. | 166206 | «Җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы буенча республика үзәге» ДАССУ | | 1 | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14. | | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министр-лыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча республика үзәге» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 15. | 160208 | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» Татарстан Респуб-ликасы ДАССУ** | 1 | 1 | | | | | 1 | | | 1 |
| 16. | 161201 | «Әгерже үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 17. | 161202 | «Ижевск шәһәренең «Россия тимер юллары-Медицина» хаста-ханәсе» ХССУ | | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 18. | 161001 | «Азнакай үзәк район хаста-ханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 19. | 161301 | «Аксубай үзәк район хаста-ханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 20. | 161401 | «Актаныш үзәк район хаста-ханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 21. | 161402 | «Стоматолог» ҖЧҖ*** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 22. | 161501 | «Алексеевск үзәк район хаста-ханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 23. | 161601 | «Әлки муниципаль районының Базарлы Матак үзәк район хаста-ханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 24. | 161602 | «Күз хирургиясе районара үзәге – Хузангай» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 25. | 160419 | «3 нче Әлмәт шәһәр поликлини-касы» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | |
| 26. | 160404 | «Перинаталь үзәге булган Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | | | | | | | |
| 27. | 160407 | «Әлмәт ашыгыч медицина ярдәме станциясе» ДАССУ | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 28. | 160410 | «Әлмәт стоматология поликли-никасы» ДАССУ*** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 29. | 160401 | «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 30. | 160425 | «Әлмәт җәмәгать сәламәтлеге һәм медицина профилактикасы үзәге» ДАССУ | | 1 | | | | | | | | |
| 31. | 160002 | «Әлмәт районара күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | 1 | | | 1 |
| 32. | 160232 | «МРТ Экспресс» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 33. | 166254 | «ФармГрупп» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 34. | 160409 | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ | | 1 | | | | | 1 | | | 1 |
| 35. | 160047 | «Варикоза нет» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 36. | 161701 | «Апас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 37. | 161801 | «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 38. | 161901 | «Әтнә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 39. | 162101 | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 40. | 162205 | «Балтач үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 41. | 160501 | «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 42. | 160502 | «Медстом» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 43. | 162001 | «Буа үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 44. | | «Кильдураз авылының республика балалар шифаханәсе» ДАССУ | 1 | | | | | | | | | |
| 45. | 162301 | «Югары Ослан үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 46. | 162401 | «Биектау үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 47. | 162402 | «Нефрология үзәге» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 48. | 162501 | «Чүпрәле үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 49. | 160608 | «АлСтом» стоматология поликлиникасы» АҖ*** | 1 | 1 | | | | | | | | |
| 50. | 160601 | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 51. | 160610 | «Кристалл Клиник» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 52. | 160611 | «Күз хирургиясе үзәге – Алабуга» ҖЧҖ | | 1 | | | | | | | | |
| 53. | 161101 | «Зәй үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 54. | 160701 | «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | |
| 55. | 162601 | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 56. | 162701 | «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 57. | 162801 | «Кукмара үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 58. | 162901 | «Лаеш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 59. | 160801 | «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | |
| 60. | 163001 | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | 1 | 1 | 1 | |
| 61. | 163101 | «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 62. | | «Дента» стоматология поликлиникасы» ҖЧҖ*** | 1 | | | | | | | | | |
| 63. | 163201 | «Минзәлә үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 64. | 163301 | «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ*** | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 65. | 160045 | Сәламәтлегенә зур ихтыяҗ булган кеше-ләр өчен «Фәрештәләргә шатлык бүләк итәбез» коммерциягә карамаган автоном оешмасы | | 1 | | | | | | | | |
| 66. | 160306 | «Медицина реабилитациясе буенча балалар үзәге» ДАССУ | 1 | 1 | | | | | 1 | | 1 | 1 |
| 67. | 160303 | «Кама Аланы район хастаханәсе» ДАССУ | 1 | 1 | 1 | 1 | | 1 | | | | |
| 68. | 160313 | «Перинаталь үзәге булган Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ** | 1 | 1 | 1 | | | | 1 | 1 | | 1 |
| 69. | 160312 | «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» ДАССУ** | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
